ГЛАВА ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д.5, с.
Ямбулатово,
422587

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Узәк ур., 5 нче йорт, Ямбулат авылы,
422587

Тел.: (84379) 36-5-18 факс: (84379) 36-5-18

2023 елның 19 ноябре № 2

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең Крестниково торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 19 ноябрендә «Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Крестниково торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?-

Мәктәп урамы буенча юлга вак таш салу өчен вак таш сатып алу һәм илтеп җиткерү, - дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 23 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 17 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен тавыш бирделәр - гражданнар җыенында 17 катнашучы; «Юк» позициясе өчен тавыш бирделәр - җыенда 0 катнашучы, тыелдылар - җыенда 0 катнашучы.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең Крестниково торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Крестниково торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?-

– Мәктәп урамы буенча юлга вак таш салу өчен вак таш сатып алу һәм илтеп җиткерү, - дигән сорау буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең Крестниково торак пункты территориясендә гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Ямбулат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: М.Н.Әхмәтҗанов